# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# «ЯҢА ТРОИЦКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
# МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

26.09.2016 № 9/2

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлегендә җирле референдумны билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «җирле референдум турында»2004 елның 25 мартындагы 23 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20, 35 статьялары, Яңа Троицкий авыл җирлеге Уставы нигезендә, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2016 елның 20 ноябренә якшәмбе көнне Яңа Троицкий авыл җирлегендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә
2. Яңа Троицкий авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе белән берлектә Яңа Троицкий авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү турында инициативаны тәкъдим итәргә.

«2016 елда яшәү урыны буенча Яңа Троицкий авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләрдән тыш, 200 (ике йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

1) Ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту:

- Яңа Троицкий авылының 1 нче зиратына кадәр юлны ремонтлау - 40000 сум;

- Яңа Троицкий авылының 2нче зиратына кадәр булган юлны ремонтлау- 73200 сум;

- Шөкрәле авылы зиратына кадәр юлны ремонтлау - 14300 сум.

2). Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге

автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Яңа Троицкий авылының Үзәк урамы буенча юлларны ремонтлау - 28 300;

- Суровка авылында тротуар төзү - 90000 сум;

- Яңа Троицкий авылында тротуар төзү - 50 000 сум.

3. Референдумны әзерләү һәм үткәрүне референдум комиссиясенә йөкләргә:

- муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе (Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясе);

- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлегенең участок сайлау комиссияләре.

4. Җирле референдум үткәрүгә бәйле чыгымнарны Яңа Троицкий авыл җирлеге бюджеты хисабына тормышка ашырырга.

5. Әлеге карарны «Якты юл» (»Светлый путь«)газетасында бастырырга.

6. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырып халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Волкова